Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге Советы

# КАРАР № 3

Биектау авылы 2024 елның 19 июне

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2023елның 02 мае “Җирле салымнар суммалары өлешендә әҗәтләрне түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында” 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Төбәк салымнары суммалары өлешендә әҗәтне түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында” 2024 елның 12 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “ Биектау авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советының 2023 елның 02 мае “Җирле салымнар суммалары өлешендә әҗәтләрне түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында” 9 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) түбәндәге эчтәлектәге 2 пунктны өстәргә:

“2. 2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә караган, каплау һәм (яки) түләтү түбәндәге нигезләр буенча мөмкин булмаган җирле салымнар суммалары өлешендә әҗәтләрне (бурычларны) түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бирәчәкләр булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 маддәсендә билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларда 500 сумнан артмаган суммада бурыч (әҗәт) булу.”;

1.2) 2, 3, 4, 5 пунктларны тиңдәшле рәвештә 3, 4, 5, 6 пунктлар дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Биектау авылы, Х. Сафиуллин урамы, 4 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Околоток-Яңасала авылы, Калинин урамы, 102 йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Чаллыбаш авылы, М. Горький урамы, 69 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль

районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Биектау авыл җирлеге Башлыгы урынбасары Р.А.Хуснуллина